КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 31 март г.Казань № 199

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре торак пункты җирләре составындагы җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләрен раслау турында» 2013 ел, 25 ноябрь, 927 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре торак пункты җирләре составындагы җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләрен раслау турында» 2013 ел, 25 ноябрь, 927 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 11 август, 581 нче; 2017 ел, 14 гыйнвар, 6 нчы; 2017 ел, 3 май, 258 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аңа түбәндәге эчтәлекле 6 нчы пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«6. «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 ел, 29 июль, ФЗ-135 нче Федераль законның $24^{18}$ статьясы белән күздә тотылган дәүләт кадастр бәясен билгеләгәндә файдаланылган мәгълүматлар дөрес булмау нигезендә Казан шәһәре торак пункты җирләре составындагы җир кишәрлекләренең дәүләт кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләренә кертелә торган, тиешле салым буенча салым базасын билгеләгәндә салым түләүчеләрнең хәлен яхшырта торган үзгәрешләр 2013 елның 1 гыйварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин